| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан<br>Зеленодольский<br>муниципальный район<br>Глава<br>муниципального образования<br>поселок городского<br>типа Нижние Вязовые** | **Татарстан Республикасы<br>Зеленодол<br>муниципаль районы<br>Карамалы тау шэһэр<br>тибындагы поселок<br>муниципаль берэмлекнен<br>Башлыгы** |

422500, ш.т.б. Карамалы Тау т., Беренче Май ур., 70

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**16.01.2017** **№01**

«ТР Зеленодольск муниципаль районы Түбән Карамалы Тау ш.т.п. Тынычлык урамы буенча ГРПНЫ техник яктан яңадан кораллландыру» линияле объекты буенча территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты буенча ачык тыңлауларны билгеләү турында

Кеше тормышының уңай шартларына, җир кишәрлекләренә һәм капиталь төзелеш объектларына хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45, 46 статьяларына таянып,

**Карар бирәм:**

1. 20.02.2017 елга Минем инициативам буенча «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Түбән Карамалы Тау ш.т.б. Тынычлык урамы буенча ГРПНЫ техник яктан яңадан коралландыру» линияле объекты буенча территорияне планлаштыру проекты һәм межалау проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.
2. Ачык тыңлауларның урынын һәм вакытын билгеләү-Карамалы Тау шәһәр җирлеге башкарма комитетының административ бинасы, Беренче Май ур., 70 йорт, киңәшмәләр залы, 15.00 сәгатьтә.
3. 2017 елның 20 гыйнварына кадәр әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә Карамалы Тау шәһәр җирлегенең мәгълүмат стендында түбәндәге адрес буенча халыкка хәбәр итәргә мөмкин: Карамалы Тау ш.т. п., Беренче Май ур., 70 йорт.
4. Проект буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризаларны, чыгыш ясау хокукы белән, Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы, Беренче Май урамы Башкарма комитетына тапшырырга кирәк. 70нче

йорт, каб.2. (эш көннәрендә 8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр). Чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирү вакыты 13.02.2017 кадәр.

5. Карамалы Тау шәһәр җирлеге башкарма комитеты:

5.1. әлеге карар нигезендә «ТР Зеленодольск муниципаль районы Түбән Карамалы Тау ш.т.п. Тынычлык ур. буенча ГРПНЫ техник яктан яңадан коралландыру» линияле объекты буенча территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты буенча гавами тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә;

5.2. халык тыңлауларының нәтиҗәләрен 2017 елның 27 февраленнән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

6. Әлеге карар рәсми халыкка җиткерелгәннән соң үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Җирлек башлыгы Ф.Н. Шәмсиев